**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**12.01.2023 ел** **№ 38**

## «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы мәдәниятен үстерү» максатчан программасына үзгәрешләр кертү турында

Биектау муниципаль районының мәдәни тормышында катнашуга һәм мәдәният учреждениеләреннән файдалануга кешенең конституциячел хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү, шулай ук гражданнарның мәдәни, музей кыйммәтләреннән файдалану мөмкинлеген, китапханә хезмәте буенча хезмәтләр күрсәтүгә, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә өстәмә белем бирүгә халык ихтыяҗларын тәэмин итү, район халкы арасында җәмгыять иминлегенә ирекле хезмәт идеяләрен пропагандалау максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы 386 номерлы карары белән расланган «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы мәдәниятен үстерү» максатчан программасына кушымта нигезендә түбәндәге редакциядә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http//vysokya-gora/tatarstan/ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Биектау муниципаль районы
башкарма комитетының 12 гыйнвар
2023 38 нче номерлы карарына
кушымта

**«2022-2024 елларга БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘДӘНИЯТЕН ҮСТЕРҮ»**

**МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ**

## Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы мәдәниятен үстерү» муниципаль программасы |
| Программаның заказчысы | «Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ |
| Программаны эшләүче | «Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесе |
| Программаның максатлары | Кешенең Биектау муниципаль районының мәдәни тормышында катнашуга һәм мәдәният учреждениеләреннән файдалануга конституциячел хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү, шулай ук гражданнарның мәдәни, музей кыйммәтләреннән файдалану мөмкинлеген, китапханә хезмәте буенча хезмәтләр күрсәтүгә, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә өстәмә белем бирүгә халык ихтыяҗларын тәэмин итү;<br>Биектау муниципаль районы мәдәният учреждениеләренең нәтиҗәле эшчәнлекләре өчен шартлар тудыру. |
| Программаның бурычлары | Биектау муниципаль районының мәдәниятен һәм сәнгатен рухи-әхлакый кыйммәтләр, мәдәни мирас һәм иҗади потенциал системасы буларак үстерү һәм саклау.<br>Мәдәният өлкәсендә муниципаль учреждениеләр челтәрен саклау һәм үстерү.<br>Район мәдәният учреждениеләренең нәтиҗәле эшчәнлеген эш формаларының камилләштерүе, матди-техник базаны ныгыту, яңа технологияләрне кертү хисабына тәэмин итү.<br>Район халкының мәдәни ялы өлкәсендә хезмәт күрсәтүләрнең күләмен һәм сыйфатын арттыру.<br>Җәмгыять үсешенең мөһим ресурсы буларак социаль-мәдәни функцияләрне тормышка ашыру өчен музейларны комплекслы үстерү.<br>Гражданнарга мәгълүмат һәм белемнәргә берничә тоткарлыксыз керү буенча конституцион хокукларны тормышка ашыруны тәэмин итәргә сәләтле китапханә хезмәте күрсәтү системасын үстерүгә, шулай ук китапханәләрдә саклана торган милли мәдәни мирасны саклап калу.<br>Милли музыка традицияләрен саклау һәм үстерү, заманча музыка сәнгатен үстерү |
| Программаның максатчан | -китапханәләрнең китапханә фондындагы нөсхәләре саны;<br>- мәдәният һәм сәнгать өлкәсенә өстәмә белем бирү учреждениеләре челтәрләре саны күрсәткече; |

| | |
|---|---|
| индикаторлары һәм күрсәткечләре | - Биектау муниципаль районы балаларының эстетик белем белән колачлау дәрәҗәсе;<br>- 14 яшькә кадәрге балалар өчен чараларның мәдәни-ял итү чараларының гомуми санындагы өлеше;<br>- узган ел белән чагыштырганда мәдәни-масса чараларында катнашучы клуб төркемнәре катнашучылары санының үсеш темплары;<br>- китапханәләрнең китап фондлары комлпектлануын үстерү;<br>- мәдәният бүлеге карамагында булган матди-техник базасын модернизацияләүне тормышка ашырган һәм тормышка ашыручы учреждениеләрнең өлеше;<br>- биналары ремонт эшләре уздыруны таләп иткән мәдәният бүлеге карамагында булган учреждениеләрнең өлеше;<br>- биналарны һәм корылмаларны төзекләндерү буенча эшләр уздырылган мәдәният бүлеге карамагындагы учреждениеләрнең өлеше. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | 2022-2024 еллар |
| Ярдәмче программалар | - «Халыкны китапханә хезмәте белән тәэмин итүне оештыру»;<br>- «Музей эшен үстерү»;<br>- «Клуб учреждениеләрен үстерү»;<br>- «Өстәмә белем бирүне тәэмин итү»;<br>- «2023-2024 елларга архив эшен үстерү»;<br>- «Өлкә белән муниципаль идарә итү системасын үстерү» |
| Программага исемлек | Программа түбәндәге бүлекләрне үз эченә ала:<br>-«Проблеманы анализлау һәм бәя бирү. Программаның максатлары»;<br>-«Программаны гамәлгә ашыруның сроклары һәм этаплары»;<br>-«Халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру»;<br>-«Музей эшен үстерү»;<br>-«Клуб учреждениеләрен үстерү»;<br>-«Балаларны өстәмә белем бирү белән тәэмин итү»;<br>-«2023-2024 елларга архив эшен үстерү»;<br>- «Бюджет чараларын тагын да тулы һәм нәтиҗәле куллануга ирешү»;<br>-«Мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту»; |
| Ярдәмче программаларны һәм Программаның төп | «Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесе, район мәдәният учреждениеләре. |

<table>
<tr><td>чараларын башкаручылар</td><td></td></tr>
<tr><td>Программаны финанслауның күздә тотылган күләме һәм чыганаклары</td><td>Программаның барлык чараларын тормышка ашыру җирле бюджеттан һәм бюджеттан тыш чыганаклардан финанслауны күз алдында тота (мәдәният учреждениеләренең үз чаралары, иганәчеләрнең чаралары);<br>Программаны финанслау күләме тиешле бюджетларны формалаштырганда ел саен төгәлләштерелә.<br><br>
<table>
<tr><td rowspan="2">Күздә тотылган финанслау чыганаклары</td><td colspan="3">Бюджет финанславы, мең сум</td></tr>
<tr><td>2022 тормышка ашыруның 1 нче елы</td><td>2023 тормышка ашыруның 2 нче елы</td><td>2024 тормышка ашыруның 3 нче елы</td></tr>
<tr><td>Барлыгы, шул исәптән:</td><td>172689.0</td><td>205222.9</td><td>187619.5</td></tr>
<tr><td>Җирле бюджет</td><td>171245.0</td><td>203778.9</td><td>186175.5</td></tr>
<tr><td>Бюджеттан тыш чыганаклар</td><td>1444.0</td><td>1444.0</td><td>1444.0</td></tr>
</table>
</td></tr>
<tr><td>Программа үтәлешен контрольдә тоту</td><td>«Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ</td></tr>
</table>

## I бүлек
## Проблеманы анализлау һәм бәяләү. Программаның максатлары

Биектау муниципаль районы мәдәни потенциалга ия – болар 36 клуб учреждениесе белән бергә «Биектау Үзәк мәдәният йорты үзәкләштерелгән системасы» МБУ, 35 филиалы белән «Биектау үзәкләштерелгән китапханә системасы» МБУ үзәк балалар китапханәсе, ике бүлек белән (Дөбъяз, Бөреле), «Салих Сәйдәшев исемендәге сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ, 1 филиалы белән (Өбрә авылындагы С.Сәйдәшев музее) «Биектау туган якны өйрәнү музее» МБУ, 37 филиалы белән «Биектау үзәкләштерелгән китапханә системасы» МБУ.

Финанс күзлегеннән чыгып караганда, мәдәният өлкәсе хәзер милли байлыкны тәшкил итүче матди кыйммәтләрне саклау, җыю бара торган социаль блок өлкәсе булып тора.

Мәдәниятне һәм сәнгатьне саклау һәм үстерү бурычларын хәл итү комплексלы якын килүне, барлык эшне заманча оештыруны, перспективалы планлаштыруны таләп итә. Әлеге программаны тормышка ашыру мәдәни мирасны саклау буенча максатчан эш алып бару һәм районның мәдәни потенциалын үстерүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк. Программа интеллектуаль, иҗади, оештыру һәм финанс мөмкинлекләрен берләштерүне күз алдында тота.

Программа булган потенциалны сакларга мөмкинлек бирә торган һәм Биектау муниципаль районы үсеше өчен яңа импульс бирүче чараларны ачыклый:

- иҗади потенциалны үстерү һәм яңадан җитештерү өчен шартлар тудыру;
- мәдәни традицияләрне һәм бердәм мәдәни киңлекне саклау;
- заманча мәдәният һәм сәнгатьнең барлык төрләренең һәм жанрларының үсешенә ярдәм итү, барлык катламнарның да мәдәни кыйммәтләрне алу мөмкинлеге өчен шартлар тудыру;
- Биектау муниципаль районы мәдәният учреждениеләренең абруен үстерү;
- һөнәри сәнгать үсешенә булышлык итү.

Әлеге Программаны тормышка ашыру гражданнарның районның мәдәни тормышында катнашу өчен иҗади ирекләрен тәэмин итүне, гражданнарның районның мәдәни тормышында катнашу өчен иҗади үсеш мөмкинлекләрен тәэмин итүне гарантияли.

Программа муниципаль районга йөкләнгән районкүләм чаралар, бәйрәмнәрне оештыру аркылы район халкының ялын оештыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Программа районкүләм смотрлар, акцияләр, бәйгеләр, фестивальләр оештыру аркылы мәдәният өлкәсендә эшләүчеләргә һөнәри белем бирү буенча эшчәнлекне күз алдында тота, бу үз чиратында кулланучыларның мәдәни хезмәт күрсәтү сыйфаты һәм мөмкинлекләр белән канәгать булу артуга, мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүләр сыйфаты артуга китерәчәк.

## II бүлек
## Программаны тормышка ашыруның сроклары һәм этаплары

| № т/б | Этап исеме | Тормышка ашыру сроклары | Көтелгән нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Программаны эшләү | 2021 елның 4 кв. | «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы мәдәниятен үстерү» муниципаль программасын раслау |
| 2 | Программаны тормышка ашыру | 2022-2024 еллар | Район халкының укуга иҗтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү өчен китапханә фондларын тулыландыру.<br>Авыл халкының мәгълүмат ресурсларына киң керү мөмкинлеген тәэмин итү.<br>Китапханә хезмәткәрләренең һөнәри дәрәҗәсен күтәрү.<br>Музей фондларын тулыландыру.<br>Музейның яңа эш формаларын эзләү эшчәнлеген стимуллаштыру.<br>Музей эшчәнлегенә яңа технологияләрне кертү.<br>Район имиджын формалаштыру.<br>Россия тарихына, Биектау муниципаль районы традицияләренә һәм мәдәни |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | мирасына хөрмәтле мөнәсәбәт, гражданлык, патриотизм тәрбияләү.<br>Караучылар аудиториясен киңәйтү; Халыкның төрле катламының мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү.<br>Клуб учреждениеләре хезмәткәрләренең квалификациясен арттыру.<br>Эшчәнлекнең инновация төрләре өчен шартлар тудыру.<br>Тәкъдим ителүче хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын арттыру.<br>Яшь талантларның иҗатын стимуллаштыру һәм ярдәм күрсәтү.<br>Һөнәри сәнгатьне популярлаштыру.<br>Янгынга куркынычсызлыгын тәэмин итү.<br>Мәдәният учреждениеләренең эчке биналарын ремонтлау. |
| 3 | Нәтиҗәләр ясау | 2024 елның 4 кварталы | «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы мәдәниятен үстерү» муниципаль программасын тормышка ашыру кысаларында мәдәният учреждениеләренең эшчәнлеген анализлау |

«2022-2024 елларга музей эшен үстерү» ярдәмче программасы Биектау муниципаль районы Музей фондын саклау, өйрәнү һәм популярлаштыру, шулай ук җәмгыять үсешенең мөһим ресурсы буларак, алар тарафыннан социаль-мәдәни функцияләрне тормышка ашыру максатыннан музейларны комплексы үстерүгә юнәлдерелгән.

«2022-2024 елларга халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру» ярдәмче программасы гражданнарга мәгълүмат һәм белемнәргә бернинди тоткарлыксыз керү буенча конституцион хокукларны тормышка ашыруны тәэмин итәргә сәләтле китапханә хезмәте күрсәтү системасын үстерүгә, шулай ук китапханәләрдә саклана торган милли мәдәни мирасны саклап калуга юнәлдерелгән.

«2022-2024 елларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү» ярдәмче программасы милли музыка традицияләрен саклау һәм үстерү, заманча музыка сәнгатен үстерүне максат итеп куя.

«Клуб учреждениеләрен үстерү» ярдәмче программасы Биектау муниципаль районы халкының мәдәният өлкәсендәге хәзерге ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыруга, халыкның төрле катламының ялын оештыру, мәдәният учреждениеләренең җәлеп итүчәлеген арттыруга юнәлдерелгән.

Программаны тормышка ашыруны финанс ягыннанан тәэмин итү законнар тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелә торган федераль, республика бюджеты

чараларын, шулай ук Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын куллануны күз алдында тота.

**«Халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру»**
**ярдәмче программасы**

Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында «2022-2024 елларга халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру» (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның заказчысы | «ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ |
| Ярдәмче программаны төп эшләп чыгаручы | Биектау муниципаль районының «Биектау үзәкләштерелгән китапханә системасы» МБУ |
| Ярдәмче программаның максаты | Гражданнарга мәгълүмат һәм белемнәргә бернинди тоткарлыксыз керү буенча конституцион хокукларны тормышка ашыруны тәэмин итәргә сәләтле китапханә хезмәте күрсәтү системасын үстерүгә, шулай ук китапханәләрдә саклана торган милли мәдәни мирасны саклап калу |
| Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Китапханә хезмәт күрсәтүенең нәтиҗәле системасын тәэмин итү.<br>2.Китапханә фондларының актуальлеген һәм сакланышын тәэмин итү.<br>3.Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы китапханәләр челтәре бердәм мәгълүмат системасын үстерү.<br>4.Һәркемгә мөмкин булган китапханәләр эшчәнлеген модернизацияләү һәм һәркем керә алырлык китапханәләрнең нәтиҗәле эшләве, кулланучыларның анда булуларының куркынычсыз һәм уңайлылыгы өчен матди-техник базасын ныгыту.<br>5.Укуны алга җибәрү өчен мәдәни-агарту эшчәнлеген җәелдерү.<br>6.Китапханәләрнең туган якны өйрәнү эшчәнлеген оештыру: эзләнүнү эше, туган якны өйрәнү мәгълүматлар базасын һәм методик-библиографик ярдәмлекләр булдыру, туган якны өйрәнү проектларын тормышка ашыру.<br>7.Берөзлексез һөнәри белем алу һәм квалификацияне күтәрү системасы үсеше. |

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның сроклары һәм этаплары | 2022-2024 еллар |
| Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре, еллар буенча бүлеп | Ярдәмче программалар фаразлау характерында булалар һәм билгеле финанс елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетын төзегәндә ел саен тәгаенләнергә тиешле. |
| Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә көтелгән ахыргы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет эффективлыгы күрсәткечләре | Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2024 елга түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>китапханә хезмәте белән колачланган район халкының артуы;<br>һәркем керә алырлык китапханәләр бердәм фондында яңа кергән басмалар өлеше артуы;<br>үзәкләштерелгән язылу исемлеге күләме арту;<br>китапханәләрнең Җыелма электрон каталогында библиографик язмалар күләме арту;<br>Интернет челтәренә чыгу мөмкинлеге булган һәркем керә алырлык китапханәләр өлеше арту;<br>заманча китапханә җиһазлары һәм мебельләр белән тәэмин ителгән китапханәләр өлеше арту;<br>модельле итеп оештырылган китапханәләр саны арту;<br>ел дәвамында кваликациясен күтәргән белгечләр өлеше, тармактагы барлык белгечләр санында арту. |

## I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенә, шул исәптән ул хәл итәргә тиешле мәсьәләләрне дә кертеп, гомуми характеристика

Һәркем файдалана алырлык китапханәләр бердәм мәгълүмати һәм мәдәни киңлек оештыруда һәм гражданнарның мәгълүмат һәм мәдәни кыйммәтләргә тоткарлыксыз керү буенча конституцион хокукларын тормышка ашыруда иң мөһим звено булып торалар.

Район барлыгы 37 һәркем керә алырлык китапханә эшли, шул исәптән Үзәк район китапханәсе, Үзәк балалар китапханәсе, 35 авыл китапханә-филиаллар. Һәркем керә алырлык китапханәләр фонды 413881 саклау берәмлеген тәшкил итә. 2023 елның 1 гыйнварына теркәлгән кулланучылар саны – 28438 кеше, шул исәптән балалар – 9000 укучы, килүләр саны – 374180 кеше.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 елның 19 октябрендәге 1683-р номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының социаль инфраструктура объектларына ихтыяҗлар нормативларын ачыклау методикасы нигезендә районның һәркем керә алырлык китапханәләр белән тәэмин ителеше 66 процентны тәшкил итә, бер китапханәгә уртача 1473 кеше туры килә (ТР буенча – 2,4 мең кеше).

1 кешегә китаплар белән тәэмин ителеш 7,6 китап, һәркем керә алырлык район китапханәләренең 1 укучысына – 14,6 китап тәшкил итә.

Район халкына һәркем мөмкин китапханәләр тарафыннан тәкъдим ителүче хезмәтләр социаль-икътисади сәясәтнең мөһим факторы булып тора, гражданнарның белем алуына һәм мәдәни үсешенә булышлык итә, районның һәрбер кешесенә мәгълүмат алуга ирекле рәвештә керү мөмкинлеген бирә.

Хәзерге вакытта китапханә өлкәсендә актуаль проблемалар булып торалар:

1. Китапханә фондларының сыйфатлы яңартылуының акрын темплары: актуаль тармак әдәбиятында, балалар әдәбиятында кискен ихтыяҗ бар, фондларның яңартылуын арттыру кирәк, язма басмаларны финанслауны арттыру.

2. ЦБС китапханәләрендә китап саклау өчен мәйданнар җитмәү.

37 китапханәдән: мәктәп бинасында – 6; мәдәният йорты һәм авыл мәдәният йорты биналарында – 26сы эшли. авыл җирлеге белән бергә – 3, ҮК аерым торучы биналарында – 1, Үзәк балалар китапханәсе үзәк китапханә бинасында – 1 урнашкан.

15594 кешегә хезмәт күрсәтә торган Биектау авыл китапханәсе өчен бина бүлеп бирү кирәк.

3. ЦБС МБУ учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту кирәк.

Район китапханәләре учреждениеләренең матди-техник базасы буенча килеп туган хәлгә анализ:

- китапханәләрнең матди-техник базасы тотрыксыз – авыл китапханәләрендә заманча китапханә җиһазлары, фондларның сакланышын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүче чаралар булмавы;
- китапханәләр физик мөмкинлекләре чикле кешеләргә хезмәт күрсәтү өчен яраклаштырылмаган;
- үзәк китапханә бинасына капиталь төзекләндерү таләп ителә.

Мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту өлкәсендә Программаның төп бурычлары:

- авыл китапханәләренең эчке биналарын ремонтлау;
- китапханә учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;
- техник җиһазларны модернизацияләү, китапханә җиһазлары, компьютер техникасы, программа белән тәэмин итү чараларын алу;

Программа бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән төп чаралар:

- Үзәк китапханә бинасын капиталь төзекләндерү.

4. Электрон рәвештә тәкъдим ителә торган хезмәт күрсәтүләрнең күләме һәм төрләрен арттыру таләп ителә. Китапханәләр тарафыннан "PROкультура РФ" порталында үз сайтларын булдыру эше бара. 2022 елның өченче кварталы ахырына әлеге порталда 37 китапханәдән 35 китапханә теркәлгән. Китапханәчеләр, шулай ук «ТР Милли электрон китапханәсе» порталында актив эшлиләр, аның кысаларында китапханәләрнең Җыелма электрон каталогы булдырыла. 2022 елда «Биектау ЦБС» МБУ китапханәләр эше турында мәгълүмат бирелгән үз сайты булдырылды, сайтның тулыландырылуы буенча эш дәвам итәчәк. Әлеге бурычны хәл итәр өчен, компьютер программалар тәэмин итү буенча белгечләр кирәк. Ярдәмче программаның чараларын тормышка ашыру халыкка мәгълүмат-китапханә хезмәте күрсәтүне камилләштерүгә ярдәм итәргә, инновацион технологияләр үсешенә, район халкына мәгълүмат ресурсларына читтән торып керә алу мөмкинлеген тәкъдим итәчәк.

Китапханә фондларының куркынычсызылыгын һәм саклынышын тәэмин итү бурычын хәл итү өчен кыйммәтле фондларны саклау буенча куркынычсызлык комплексլы системасын эшләү һәм кертү, биналарның норматив физик һәм санитар-

гигиена халәтен тәртиптә тоту, куркынычсызлык чараларын заманча техник чаралар белән җиһазландыру тиешле.

5. Биектау муниципаль районы «Биектау ҮКС» МБУсендә 53 хезмәткәр эшли. Аларның 35е югары белемле, шул исәптән китапханә буенча – 29, урта-һөнәри – 18, шул исәптән китапханә буенча – 15 кеше. Белгечләр белән тәэмин ителеш 86,7 %ны тәшкил итә.

Һөнәри белем бирү системасы үсеше, шул исәптән белем бирүнең заманча методлары, төрле эш формалары – семинарлар, һөнәри осталык конкурслары, тренинглар, эшлекле уеннар һ.б. китапханә хезмәткәрләренең тиешле квалификация дәрәҗәсенә ярдәм итәргә тиеш.

2022 - 2024 елларга Татарстан Республикасы Биектау районында китапханә эшен үстерү буенча ярдәмче программасы Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү буенча дәүләт программасы һәм башка проектлар белән үзара бәйләнештә.

## II. Ярдәмче программаның максатлары, бурычлары, аны тормышка ашыруның ахыргы нәтиҗәләре һәм сроклары тасвирламасы

Ярдәмче программаның максатлары – гражданнарга мәгълүмат һәм белемнәргә бернинди тоткарлыксыз керү буенча конституцион хокукларны тормышка ашыруны тәэмин итәргә сәләтле китапханә хезмәте күрсәтү системасын үстерү, китапханәләрдә саклана торган милли мәдәни мирасны саклап калу.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. Китапханә хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәле системасын тәэмин итү;
2. Китапханә фондларының актуальлеген һәм сакланышын тәэмин итү;
3. Татарстан Республикасы китапханәләр челтәре бердәм мәгълүмат системасы үсеше;
4. Китапханәләр эшчәнлеген модернизацияләү һәм китапханәләрнең нәтиҗәле эшләве, кулланучыларның анда булуларының куркынычсыз һәм уңайлылыгы өчен матди-техник базасын ныгыту;
5. Укуны алга җибәрү өчен мәдәни- агарту эшчәнлеген җәелдерү;
6. Китапханәләрнең туган якны өйрәнү эшчәнлеген оештыру: эзләнү эше, туган якны өйрәнү мәгълүматлар базасын һәм методик-библиографик ярдәмлекләр булдыру, туган якны өйрәнү проектларын тормышка ашыру;
7. Берөзлексез һөнәри белем алу һәм квалификацияне күтәрү системасын үстерү.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру срогы – 2022-2024 еллар.

## III. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү

Ярдәмче программалар фаразлау характерында булалар һәм билгеле финанс елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетын төзегәндә ел саен тәгаенләнергә тиешле.

## IV. Ярдәмче программаның икътисади һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Ярдәмче программаны тормышка ашыруның төп көтелгән нәтиҗәләре:

- төрле мәгълүмат чыганакларында саклана торган документлар белән китапханә фондларын тулыландыруны тәэмин итү һәм фондларның сыйфатлы характеристикаларын яхшырту аркылы китапханә фондларының оптималь моделен булдыру; китапханә фондларының яңартылуын арттыру;
- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы китапханәләр Җыелма электрон каталогы күләмен арттыру;
- китапханәләрнең мәгълүмати һәм белем бирү эшчәнлеген активлаштыру, укучыларга хезмәт күрсәтү формалары һәм юнәлешләрен киңәйтү;
- халыкка мәгълүмати һәм китапханә хезмәте күрсәтүне яхшырту, Интернет челтәренә керү мөмкинлекләрен киңәйтү.

Ярдәмче программаны тормышка ашыруның төп социаль эффекты – халыкның барлык социаль группалары өчен китапханәләргә керү мөмкинлеген тәэмин итү, китапханәләрнең заманча үсешенә ярдәм итү, китапханәчеләрнең эшләве өчен уңайлы шартлар тудыру һәм китапханәләрдән кулланучыларга хезмәт күрсәтү сыйфатын арттыру, җәмгыятьтә китапханәләрнең дәрәҗәсен һәм ролен арттыру, китапханәләрнең укуны һәм китапларны алга чыгару буенча мәдәни-агарту эшчәнлеге киңәюе, буш вакытларны оештыру һәм халыкның барлык категорияләрен укуга җәлеп итү буенча китапханәләрнең эшен камилләштерү, китапханә эше өлкәсендә бюджет чаралары чыгымнарын оптимальләштерү.

| | Программа чараларының исеме | Финанслау чыганаклары | Финанслау күләме, мең сум | Фаразланган финанслау күләме, мең сум. | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022ел | 2023ел | 2024ел |
| 1. | Халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру | Җирле бюджет<br>Бюджеттан тыш | 91682.8<br>30.0 | 28847.6<br>10.0 | 31528.4<br>10.0 | 31306.80<br>10,0 |
| 2. | ЦБСның китап фондларының кирәкле тулылыгын комплектлауны оештыру һәм тәэмин итү | Җирле бюджет | 500.0 | 100.0 | 100.0 | 300.0 |
| 4. | Вакытлы матбугатка язылуны оештыру | Җирле бюджет | 696.0 | 198.0 | 198,0 | 300.0 |
| | | Җирле бюджет | 92878.8 | 29145.6 | 31826.4 | 31906.80 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы: | Бюджеттан тыш | 30.0 | 10.0 | 10.0 | 10.0 |

**«2022-2024 елларга музей эшен үстерү» Ярдәмче программасы**

**Программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2022-2024 елларга музей эшен үстерү» (алга таба – ярдәмче программа). |
| Ярдәмче программаның заказчысы | «Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ |
| Ярдәмче программаны төп эшләүче | Биектау муниципаль районы «Биектау туган якны өйрәнү музее» МБУ |
| Ярдәмче программаның максаты | Җәмгыять үсешенең мөһим ресурсы буларак социаль-мәдәни функцияләрне тормышка ашыру өчен музейларны комплекслы үстерү |
| Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Биектау муниципаль районы Музей фондларының дәүләтнеке булган өлешен саклау, өйрәнү һәм комплектлау.<br>2. Биектау муниципаль районы Музей фондларын популярлаштыру.<br>3. Музейлар тарафыннан мәдәни һәм фәнни-агарту, белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыру.<br>4. Музейларны мәгълүматлаштыру. |
| Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә көтелгән ахыргы нәтиҗәләр (нәтиҗәләргә бәя бирү индикаторлары) һәм аның бюджет эффективлыгы күрсәткечләре | Ярдәмче программаны тормышка ашыру 2024 елга түбәндәгеләрнең артуына ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>төп фондның реставрацияләнгән әйберләренең реставрация таләп ителгән дәүләт исәбенә һәм саклауга куелган музейларның төп фондларының әйберләре саныннан өлешенең ел ахырына ел башына чагыштырмасы 93 процентка кадәр;<br>саклау-янгын куркынычсызлыгы системалары белән җиһазландырылган музей мәйданнары өлеше, 100 процентка кадәр;<br>актив күрсәтүдә кулланган музей әйберләренең төп фондның гомуми әйберләр санына чагыштырма авырлыгы 95 процентка кадәр;<br>хисап елында музейларда булуның алдагы елдагыга чагыштырмасы 34 процентка кадәр; |

| | |
|---|---|
| | социаль якланмаган гражданнар төркеме һәм мөмкинлекләре чикле затлар тарафыннан хисап елында музейларга баруның алдагы елдагыга чагыштырмасы 50 процентка кадәр;<br>хисап чорында ачылган үз фондларыннан күргәзмәләр санының алдагы чорга чагыштырмасы 94 процентка кадәр;<br>электрон каталогка кертелгән музей әйберләренең саны, музей әйберләренең гомуми санына карата 20 процентка кадәр;<br>компьютерлаштырылган эш урыннары санының гомуми хезмәткәрләр санына чагыштырмасы 100 процентка кадәр. |

## I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенә, шул исәптән чишелешенә ул юнәлдерелгән мәсьәләләргә гомуми характеристика

Биектау муниципаль районы музей челтәре үз эченә Биектау муниципаль районының 1 район туган якны өйрәнү музеен һәм туган якны өйрәнү музееның структур бүлекчәсен: Өбрә авылындагы Салих Сәйдәшев музеен үз эченә ала.

Биектау муниципаль районы район туган якны өйрәнү музеенда 1685 саклау берәмлеге саклана. Туган якны өйрәнү музеенең бүлекчәсендә Салих Сәйдәшев музеенда 667 саклау берәмлеге саклана.

Музейларга килүчеләрнең төп төркеме булып балалар аудиториясе, яшьләр, килүчеләрнең ташламалы төркеме (пенсионерлар, инвалидлар һ.б.), гаилә аудиториясе тора. Бүгенге көндә музейлар тарафыннан эшләп чыгарыла торган программалар һәм акцияләр нәкъ менә әлеге максатчан төркемнәргә юнәлдерелгән.

Район халкының мәдәни кыйммәтләрен күрә алу мөмкинлеге музейлар тарафыннан күргәзмәләр уздыру юлы белән генә түгел, ә күчерелеп йөртелә торган күргәзмәләр, массалы чаралар уздыргандагы күргәзмәләр, ТР музее белән бергә оештырыла торган күргәзмәләр оештыру кебек эш формалары белән дә тормышка ашырыла. Музей әйберләрен актив күрсәтүдә катнаша торган әйберләрнең чагыштырма авырлыгы 75 процент.

Музейларның базаларының матди-техник үсешен хәл итүне таләп итә торган музей эшчәнлегенең проблемалары:

мәдәни-белем бирү, фәнни-мәгърифәт максатларында барлык Музей фондын пассив куллану;

дәүләт музейларының кирәгенчә мәгълүматлаштырылмавы;

инфраструктура начар үсеш алганга, мәдәни туризмның җитәрлек үсеш алмавы.

## II. Ярдәмче программаның максаты, бурычлары, аны тормышка ашыруның сроклары һәм ахыргы нәтиҗәләре тасвирламасы.

Ярдәмче программаның максаты булып җәмгыять үсешенең мөһим ресурсы

буларак, алар тарафыннан социаль мәдәни функцияләрне тормышка ашыру өчен музейларны комплекслы үстерү санала.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. Музей фондларының дәүләт өлешен саклау, өйрәнү һәм комплектлау.
2. Музей фондларының дәүләт өлешен популярлаштыру.
3. Музейлар тарафыннан мәдәни һәм мәгърифәт, белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыру.
4. Музейларны мәгълүматлаштыру.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру сроклары - 2022-2024 еллар.

Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында булалар һәм билгеле финанс елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетын төзегәндә ел саен тәгаенләнергә тиешле.

Биектау туган якны өйрәнү музее эшчәнлеге район музейларына агын да активрак рәвештә яшьләрне, мәктәп укучыларын, район халкын җәлеп итүгә булышлык итүче район халкына рухи һәм патриотик тәрбия бирүгә, бигрәк тә үсеп килүче буынга, яңа экспозицияләрне оештыру һәм булганнарын яңартуга, яңа мәдәни-белем бирү чараларын эшләүгә юнәлдерелгән.

<u>2023 елның 1 гыйнварына Биектау туган якны өйрәнү музее эшчәнлеге күрсәткечләре</u>

| | «Биектау туган якны өйрәнү музее» МБУ | «Биектау туган якны өйрәнү музее» МБУнең С. Сәйдәшев музее филиалы |
|---|---|---|
| Килүчеләр саны | 3495 | 1334 |
| Экскурсияләр | 37 | 36 |
| Лекцияләр | 5 | 11 |
| Күргәзмәләр | 47 | 7 |
| Массакүләм чаралар | 19 | 17 |
| Белем бирү программалары саны | 23 | 2 |
| Төп фонд | 1723 | 396 |
| Фәнни-ярдәмче фонд | 680 | 328 |
| Төп фондка кертемнәр | 10 | 12 |
| Фәнни-ярдәмче фондка кертемнәр | 20 | 28 |

Музей эше үсешенә юнәлдерелгән чаралар:

| № т/б | Программа чараларының исеме | Финанслау чыганаклары | Финанслау күләме, мең сум. | Фаразланган финанслау күләме, мең сум. | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 | 2023ел | 2024ел |
| 1 | «Биектау туган якны | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | өйрәнү музее» МБУ һәм С.Сәйдәшев музее базасында үткәрелә торган чараларны тәэмин итү | Җирле бюджет<br><br>Бюджеттан тыш | 12871.5<br><br>30.0 | 4162.9<br><br>10.0 | 4346.7<br><br>10.0 | 4361.9<br><br>10.0 |
| | БАРЛЫГЫ: | Җирле бюджет<br><br>Бюджеттан тыш | 12871.5<br><br>30.0 | 4162.9<br><br>10.0 | 4346.7<br><br>10.0 | 4361.9<br><br>10.0 |

**«2022-2024 елларга клуб учреждениеләрен үстерү»**
**ярдәмче программасы**

**Паспорт**

| | |
|---|---|
| Муниципаль ярдәмче программаның исеме | «2022-2024 елларга клуб учреждениеләрен үстерү» |
| Муниципаль ярдәмче программаның максаты | Биектау муниципаль районы территориясендә бердәм мәдәни киңлеген булдыру һәм саклау;<br>- мәдәният учреждениеләренең муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар, мәгариф системасы учреждениеләре, массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗади һәм дини оешмалар белән ведомствоара хезмәттәшлеген үстерү;<br>- халыкта гражданлык бердәйлеге, әхлакый-рухи һәм толерантлык дөньяга карашларын формалаштыру буенча эшчәнлекне тормышка ашыру;<br>- эш юнәлешләрен һәм формаларын камилләштерү;<br>- мәдәни-ял итү учреждениеләрендә чараларның сыйфатын арттыру;<br>- КДУ учреждениеләрен методик һәм мәгълүмати тәэмин итү. |
| Муниципаль ярдәмче программаның бурычлары | Биектау муниципаль районы тарихи-мәдәни мирасын саклау, мәдәниятен, сәнгатен үстерү һәм популярлаштыру өчен шартлар тудыру.<br><br>План нигезендә программалы массакүләм һәм бәйрәм мәдәни-массакүләм чаралары уздыру.<br><br>Мәдәни-ял итү чаралары катнашучыларының санын |

| | |
|---|---|
| | арттыру.<br><br>Халыкта гражданлык бердәйлеген формалаштыручы, иҗади потенциалны ачучы, толерантлыкны тәрбияләүче, этникара һәм конфессиара мөнәсәбәтләр мәдәниятен тәэмин итүче «Мәдәният» өлкәсендә системаны үстерү һәм модернизацияләү |
| Муниципаль ярдәмче программаның муниципаль заказчысы | «Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ |
| Муниципаль ярдәмче программаны эшләүче | Биектау районы муниципаль районы «Үзәкләштерелгән системаның үзәк мәдәният йорты» МБУ |
| Муниципаль ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2022-2024 еллар |
| Муниципаль ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның планлаштырылган нәтиҗәләре | Төрле дәрәҗәдәге конкурс, фестивальләрдә катнашкан катнашучыларның саны арту;<br>Клуб берләшмәләре һәм үзешчән халык иҗаты катнашучылары алган дипломнар, премияләр саны арту;<br>Программалы массакүләм һәм мәдәни-масса чарарлары катнашучыларының өлеше арту;<br>Үзешчән иҗади клуб берләшмәләре һәм аларда катнашучылар саны арту;<br>Түләүле нигездә чаралар саны арту |

## I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенә, шул исәптән чишелешенә ул юнәлдерелгән мәсьәләләргә гомуми характеристика

Җәмгыять үсешенең хәзерге заман этабының бер үзенчәлеге булып кешеләрнең рухи тормышын оештыручы факторларның берсе буларак мәдәниятнең социаль роле үсү тора. Шул ук вакытта мәдәният кешелекнең рухи тәҗрибәсе булып кына түгел, ә һәрбер кешенең иҗатка сәләтен формалаштыручы, кешелек яшәешенә нигез салучы, цивилизацияле тормыш кыйммәтләре һәм формаларын саклау сәләте буларак та алга чыга. Җәмгыятьнең мәдәни үсешенең кирәкле критерие булып кешенең иҗади көчләре, сәләтләре һәм талантлары барлыкка килүе һәм үсеше өчен кирәкле шартлар булуы тора. Халыкның тормыш сыйфатын тәшкил итүче мәдәни яхшыртуга юнәлдерелгән мәсьәләләрне хәл итү җирле үзидарә органнарының мәдәният өлкәсендәге вәкаләтләрен тормышка ашырып ачыклана һәм әлеге мәсьәләләрне программа-максат методлары нигезендә хәл итәргә кирәк. Муниципаль ярдәмче программаны тормышка ашыру мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга юнәлдерелгән – бу заманча шартларда Биектау муниципаль районының социаль-икътисади үсешендә мәдәниятне иң мөһим ресурсларның берсе дип тануны билгеләүче конкрет адымнар.

Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру мәдәният эшчәнлегенең барлык субъектлары катнашында социаль мөһим максатларга ирешергә мөмкинлек бирәчәк, бюджет чараларын нәтиҗәле тотуны тәэмин итәчәк һәм түбәндәгеләргә булышлык итәчәк:

1.Мәдәният, сәнгать үсеше өчен шартлар тудыру һәм тарихи-мәдәни мирасны саклап калу һәм популярлаштыру.

2.План нигезендә программалы массакүләм һәм бәйрәм мәдәни-массакүләм чаралар уздыру.

ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

Мәдәният-ял итү юнәлешендәге системаны модернизацияләү.

Әлеге процессны камилләштерү буенча чаралар системасы күз алдында тота:

- хәзерге заман этабында клуб, китапханә, музей системасында халык белән эшләү буенча өстенлекле юнәлешләрне билгеләү;
- инновацион формалар һәм методларны үстерү;
- районның муниципаль берәмлекләре белән үзара мөнәсәбәтне тәэмин итү;
- мәдәни-ял итү чараларын популярлаштыру.

Мәдәният-ял итү учреждениеләрендә мәгълүмати, фәнни-теоретик һәм методик тәэмин итү.

- “Мәдәният” өлкәсендә программа һәм методикалар комплексын эшләү;
- балаларда, яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә патриотик тәрбия формалары, методлары һәм чараларын эшләп чыгару;
- районның социаль-икътисади үсешендә мәдәният учреждениеләренең киң кулланугa күбрәк шартлар тудыру;
- халыкның иҗади потенциалы үсешенә булышлык итү;
- үз эшләрен стимуллаштыру максатларында иреклеләр (волонтерлык) һәм коммерциягә карамаган оешмаларга, шул исәптән авыл җирлегендә, социаль-мәдәни проектларны гамәлгә ашыру буенча, ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар.

**Район клуб учреждениеләре үсеше өлкәсендә**
**Программаның төп бурычлары:**

Клуб учреждениеләренең төп эшчәнлеге халыкның төрле катламының ял итүен оештыруга юнәлтелгән, шул исәптән массакүләм чаралар уздыру, концерт һәм конкурс прораммалары, бәйрәмнәр, театральләштерелгән тамашалар, тематик кичәләр, клуб берләшмәләренең эшен оештыру, Россиякүләм, төбәк, өлкә, зона һәм район смотрконкурсларында һәм фестивальләрендә катнашуга юнәлдерелгән. Район территориясендә халыкның традицион мәдәниятенә ярдәм итү һәм үстерү. Район клуб учреждениеләре эшчәнлегенә, “халык” исеме бирелгән коллективларга ярдәм итү, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә халыкка сыйфатлы хезмәт күрсәтүне оештыру, мәдәнимәгълүмати пространствоны үстерү. Мәдәни-ял итү эшчәнлеге белгечләренең квалификациясен арттыру.

Куелган бурычларны тормышка ашыру өчен шартлар белән тәэмин итү түбәндәге чараларны тормышка ашыруны күз алдында тота:

| № т/б | Программа чараларының исеме | Финанслау чыганаклары | Финанслау күләме барлыгы мең сум | Фаразлаган финанслау күләме, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022ел | 2023ел | 2024ел |
| 1. | Район халкына социаль-мәдәни, мәгърифәт, күңел ачу характерындагы төрле хезмәтләр күрсәтү, сәнгать иҗаты белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру | Җирле бюджет<br><br>Бюджеттан тыш | 326891.9<br><br>1266.0 | 98314.7<br><br>422,0 | 122983.5<br><br>422.0 | 105593.7<br><br>422,0 |
| 2. | «Созвездие-Йолдызлык» яшьләр эстрада сәнгате фестивален уздыру | Җирле бюджет | 1350.0 | 450,0 | 450,0 | 450.0 |
| 3. | Мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре өчен яңа җиһазлар һәм инвентарь сатып алу | Җирле бюджет | 4950.0 | 1650.0 | 1650.0 | 1650.0 |
| 4. | Сәхнә костюмнары алу, тегү | Җирле бюджет | 3000.0 | 1000.0 | 1000.0 | 1000.0 |
| 5. | Тематик баннерлар, стендлар эшләү. | Җирле бюджет | 450.0 | 150.0 | 150.0 | 150.0 |
| 6. | «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент»ын үтәү чаралары | Җирле бюджет | Өстәмә керемнәр булганда | Өстәмә керемнәр булганда | Өстәмә керемнәр булганда | Өстәмә керемнәр булганда |
| | БАРЛЫГЫ: | Җирле бюджет<br><br>Бюджеттан тыш | 339641.9<br><br>1266.0 | 101564.7<br><br>422.0 | 126233.5<br><br>422.0 | 108843.7<br><br>422.0 |

**«Өстәмә белем бирүне тәэмин итү» Ярдәмче программасы**
**Программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2022-2024 елларга Өстәмә белем бирүне тәэмин итү (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның заказчысы | «Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ |
| Ярдәмче программаны төп эшләүче | ТР Биектау муниципаль районы «Салих Сәйдәшев исемендәге сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ |
| Ярдәмче программаның максаты | Федераль дәүләт таләпләренә нигезендә сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирүнең комплекслы үстерү |
| Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Халыкның заманча ихтыяҗлары нигезендә мәктәптә яңа бүлекләр һәм белгечлекләр ачу һәм үстерү.<br>2.Музыкаль белемнең популярлыгын һәм сорау булуын истә тотып, укучылар һәм укытучыларның контингентын арттыру.<br>3.Федераль дәүләт таләпләренә туры килгән һөнәр алды программаларын кертү.<br>4.Укучыларның музыкаль-эстетик тәрбиясен тагын да күбрәк популярлаштыру.<br>5.Мәктәп тарафыннан тагын да киңрәк мәдәни, фәнни-агарту, белем бирү эшчәнлеген җәелдерүне тормышка ашыру.<br>6.Район ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен мәктәпне тәмамлаучыларның һөнәри ориентациясе. |
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның сроклары һәм этаплары | 2022-2024 еллар |
| Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре, елларга бүлеп | Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында булалар һәм билгеле финанс елына Биектау муниципаль районы бюджетын төзегәндә ел саен тәгаенләнергә тиешле |
| Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын | Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2024 елга түбәндәгеләрнең артуына ирешергә мөмкинлек бирәчәк: |

| | |
|---|---|
| гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет эффективлыгы күрсәткечләре | - мәктәпнең ихтыяҗ булган яңа бүлекләре һәм белгечлекләре;<br>- мәктәп педагогларының квалификациясен арттыру;<br>- мәктәп укытучыларын һөнәри яңадан әзерләү;<br>- мәдәни һәм педагогик тәҗрибә белән алмашу;<br>- мәктәпнең методик эшләре (конференция, мастер-класс һ.б.);<br>- конкурс, концерт һәм фестиваль эшчәнлегендә катнашу;<br>- район халкының күпчелек өлешен сәнгатькә тарту һәм җәлеп итү |

2022 елның 1 сентябренә мәктәптә 603 кеше белем ала.
Укыту 12 белгечлек буенча алып барыла:
- фортепиано 164 (27,1 %)
- халык уен кораллары (баян, аккордеон, думбра, балалайка, гитара) - 120 (19,9%)
- кыллы-смычоклы (скрипка) – 75 (12,4%)
- сәнгать - 82 (13,6%)
- хореография - 107 (17,7%)
- вокал - 34 (5,6%)
- өреп уйнала торган инструментлар (курай, саксафон) - 21 (3,4%)

2020 елның сентябреннән тавыш режиссурасы белгечлеге ачылды. Район халкында зур ихтыяҗ булу сәбәпле сәнгать мәктәбенең сәнгать, хореография, вокаль бүлекләре киңәйтелде.

Мәктәп укытучылары контингенты 50 кеше, аларның 29ы югары квалификация категориясенә, 16сы- беренче категориягә ия. 1 педагог Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә, 6 педагог – Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә, 3 укытучы күкрәк билгесе белән бүләкләнгән, 1 педагог педагогия фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсенә ия.

Сәнгать мәктәбе укучылары һәм педагоглары Халыкара, Россиякүләм, өлкә, зона, районара һәм район чараларында, конкурсларында, фестивальләрендә катнашалар: төрде дәрәҗәдәге чараларда һәм конкурсларда катнашкан балалар саны – 92%, алар арасыннан халыкара, россиякүләм һәм республика дәрәҗәсендәге җиңүчеләр һәм призлы урын алучылар – 83%.

Укытучыларның һөнәри осталыгын күтәрү буенча системалы эш алып барыла: ачык дәресләр үткәрелә, республика һәм район дәрәҗәсендә мастер-класслар оештырыла, сәнгать мәктәбе базасында республика семинарлары үткәрелә.

Программа кысаларында хәл ителә торган бурычларга керәләр:
- музыкаль белем бирүне популярлаштыру;
- сәләтле балаларны ачыклау һәм үстерү булдыру һәм аларның киләчәктәге һөнәри ориентациясе өчен шартлар тудыру;
- балалар һәм яшүсмерләргә музыкаль белем алу өчен шартлар тудыру;
- фестиваль, конкурс, күргәзмәләрдә катнашу;

һөнәри һәм башкару осталыгын арттыру максатларыннан мастер-класслар, фәнни-практик конференцияләр оештыру һәм уздыру.

Программа буенча чаралар районда мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирү системасын саклау һәм үстерүгә юнәлдерелгән:

| № | Программа чараларының исеме | Финанслау чыганаклары | Финанслау күләме, мең сум | Фаразланган финанслау күләме, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022ел | 2023ел | 2024ел |
| 1. | Балалар һәм яшүсмерләргә музыкаль белем алу өчен шартлар тудыру | Җирле бюджет<br>Бюджеттан тыш | 110740.0<br>1806.0 | 34834.4<br>602.0 | 37950.0<br>602.0 | 37955.6<br>602.0 |
| 2. | Районкүләм һәм районара балалар башкаруында түбәндәге номинацияләрдә конкурс-фестивальләр уздыру:<br>- фортепиано;<br>- халык уен кораллары;<br>-вокал;<br>-хореография;<br>-рәсем сәнгате | Бюджеттан тыш | 150.0 | 50.0 | 50.0 | 50.0 |
| 3. | Мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре өчен музыкаль инструментлар алу һәм ремонтлау | Бюджеттан тыш | 1050.0 | 350.0 | 350.0 | 350.0 |
| | БАРЛЫГЫ: | Җирле бюджет<br>Бюджеттан тыш | 110740.0<br>3006.0 | 34834.4<br>1002.0 | 37950.0<br>1002.0 | 37955.6<br>1002.0 |

**«2023-2024 елларга архив эшен үстерү» ярдәмче программасы**
**Ярдәмче программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2023-2024 елларга архив эшен үстерү» (алга таба - Ярдәмче программасы) |
| Ярдәмче программаның заказчысы | Биектау муниципаль районы башкарма комитеты |
| Ярдәмче программаны төп эшләүче | «Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУнең мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесе |
| Программаның | Гражданнар, җәмгыять һәм дәүләт |

| | |
|---|---|
| максатлары | мәнфәгатьләрендә архив эше белән идарә итү |
| Программаның бурычлары | Биектау муниципаль районының Архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклауны, исәпкә алуны, туплауны һәм алардан файдалануны тәэмин итү |
| Программаны гамәлгә ашыруның сроклары һәм этаплары | 2023 - 2024 еллар |
| | |
| Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре, елларга бүлеп | Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Биектау муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 2837.1 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br><br>2023 ел - 1578.8 мең сум;<br><br>2024 ел – 1258.3 мең сум;<br><br>Искәрмә: Ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында һәм тиешле финанс елына һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш |
| | |
| Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) елларга бүлеп һәм аның бюджет эффективлыгы күрсәткечләре | Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2025 елга түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>Муниципаль архив биналарының архив документларын даими саклауны тәэмин итә торган норматив шартларга туры килү дәрәҗәсенә, 90 процентка кадәр;<br>Билгеләнгән вакытларда архивлар тарафыннан башкарылган соратуларның бер ел эчендә кергән соратуларның гомуми күләмендә өлеше, 99 процентка кадәр |

**1. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенә, шул исәптән чишелешенә ул юнәлдерелгән мәсьәләләргә гомуми характеристика**

Биектау муниципаль районының Архив фонды республика халыкларының тарихи-мәдәни мирасының иң мөһим состав өлеше булып тора, аның нигезендә җәмгыять үзенә бүгеннән үткәнгә һәм киләчәккә карый ала. Бу мирасны саклау бүген, беркайчан булмаганча, кешеләргә һәм җәмгыятькә дәүләтчелек нигезләрен саклау, җәмгыятьтә рухи-әхлакый кыйммәтләрне торгызу, ватанпәрвәрлек һәм Ватанга мәхәббәт формалаштыру, кеше шәхесенең гармонияле үсеше өчен кирәк. Архивлар иҗтимагый процесслар эволюциясен терки торган тарихи чорларның дәвамчанлыгының мөһим звеносы булып тора.

Архивларда саклана торган документларның сакланышын тәэмин итү өчен архив биналарында һәм бүлмәләрендә саклау өчен оптималь (норматив) шартлар тудыру зарур. Норматив режимнар - янгынга каршы, каравыл, температура-дымлылык, яктылык, санитария-гигиена.

Архивлар янгын куркынычы аеруча зур булган объектлар рәтенә керә, чөнки аларда документлар яна торган чыганакларда (кәгазьләр, пленкалар) саклана.

Муниципаль архивта безнең көннәргә кадәр 35 меңнән артык эш саклана. Архивларда саклана торган фәнни-тарихи кыйммәттән тыш, зур социаль әһәмияткә ия, чөнки социаль-хокукый мәгълүматны үз эченә алалар. Саклауның норматив режимнарын үтәмәү аркасында архив документларын югалту район гражданнарын аларның хезмәт стажы, бүләкләнү, реабилитацияләнү һәм башкалар турында кирәкле мәгълүмат алу мөмкинлегеннән мәхрүм итәргә мөмкин.

Архивларның куркынычсызлыгын, документларны саклауның норматив режимнарын тәэмин итүнең әһәмиятен аңлап, Биектау муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы архив бүлеге бу юнәлештә максатчан эш алып бара.

Әмма, күрелә торган чараларга карамастан, архив документлары хәзерге вакытта аларның сакланышын тулысынча тәэмин итми торган шартларда саклана.

Янгын һәм саклау куркынычсызлыгын алга таба да ныгыту таләп ителә. Архив биналарын автомат, газ янгын сүндерү системасын җиһазландырырга кирәк. Иң кискен проблемаларның берсе - температура-дымлылык режимын үтәү. ГОСТ 55.6-85 «Кәгазь чыганакларда документлар. Дәүләт саклавы кагыйдәләре. Техник таләпләр» нигезендә 17-19˚С температура һәм 50-55% якынча дымлылык нормаларында аның үтәлмәве документларның картаю процессларын тизләтә. Барлыкка килгән вентиляция системасы әлеге режимны үтәүне тәэмин итми, аны алыштырырга кирәк.

Саклыкны тәэмин итү чаралары системасында документларның иминият күчермәсе аерым урын алып тора, ул документлар мәгълүматын саклап калу мөмкинлеген бирә. Моннан тыш, бер үк вакытта булдырыла торган позитив пленкада файдалану фонды асылда аеруча кыйммәтле документларны файдаланудан алуны тәэмин итә. Архивларда документлар цифрлаштыру торган саен күбрәк тарала, бу төп нөсхәләргә мөрәҗәгать итмичә документларны яңадан торгызу һәм мәгълүматтан файдалануның киң мөмкинлекләрен һәм перспективаларын бирә. Бу эшне активлаштыру өчен архивларга тиешле техника сатып алырга кирәк.

## II. Ярдәмче программаның максаты, бурычлары, аны тормышка ашыруның сроклары һәм ахыргы нәтиҗәләре тасвирламасы

Подпрограмманың максаты - гражданнар, җәмгыять һәм дәүләт

мәнфәгатьләрендә архив эше белән идарә итү. Әлеге максатны гамәлгә ашыру Биектау муниципаль районының Архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклауны, исәпкә алуны, туплауны һәм алардан файдалануны тәэмин итү бурычын хәл итүне күздә тота.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру сроклары - 2022-2024 еллар.

**III. Ярдәмче программаны ресурс белән тәэмин итүне нигезләү.**

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Биектау муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән - 2 837.1 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

2023 ел - 1 578.80 мең сум;

2024 ел - 1 258.30 мең сум.

Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле финанс елына Биектау муниципаль районы бюджетын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

**IV. Ярдәмче программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү**

Биектау муниципаль районының муниципаль архивларда саклана торган Архив фонды документлары гражданнарның, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең XX гасырдан алып бүгенге көнгә кадәр матди һәм рухи тормышын чагылдыра һәм республика халыкларының тарихи-мәдәни мирасының, мәгълүмати һәм интеллектуаль байлыгының әһәмиятле өлеше булып тора. Аларда аның торгызылуының һәм үстерелүенең хокукый һәм оештыру нигезләре чагылыш тапкан, район үсешен тәэмин итү, барлык муниципаль структураларның нәтиҗәле эшләве өчен кирәкле белешмәләр бар.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру муниципаль милек булган әлеге документларның юкка чыгу куркынычын киметергә, районның тарихи-документаль мирасына һәм мәгълүмат потенциалына зыянны, моннан килеп чыга торган дәүләт институтлары, мәдәният, фән эшчәнлеге өчен барлык тискәре нәтиҗәләр белән, гражданнарның, шул исәптән аларның социаль ярдәм алуга бәйле мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле мәгълүмат алуга һәм файдалануга конституциячел хокукларын тәэмин итүгә зыянны булдырмый калырга мөмкинлек бирәчәк. Ярдәмче программаның социаль нәтиҗәләренә муниципаль архивлар хезмәткәрләренең һәм архив документларыннан файдаланучыларның хезмәт шартларын яхшыртуны кертергә кирәк.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның иң мөһим икътисадый нәтиҗәсе буларак, янгыннар барлыкка килү нәтиҗәсендә мөлкәт юк ителүдән матди югалтуларны минимальләштерү булырга тиеш. Муниципаль архив биналарының һәм мөлкәтләренең янгын, шулай ук сак иминлеге дәрәҗәсен арттыру тәэмин ителәчәк.

Ярдәмче программа турыдан-туры Биектау муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге эшчәнлегенең стратегик максатына ирешүгә (районның Архив фонды документларын һәм гражданнар, җәмгыять, дәүләт мәнфәгатьләрендә башка архив документларын саклауны, исәпкә алуны, туплауны һәм файдалануны тәэмин итүгә) юнәлтелгән.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

- документларны саклау өчен уңайлы шартлар тудырырга;

- документларның төп нөсхәләрен югалткан яисә зарарлаган очракта документаль мәгълүматны саклау максатларында уникаль һәм аеруча кыйммәтле документларның иминият фондын булдыруга;
- муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын арттырырга, архив документларында булган мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген киңәйтергә.

## «Өлкә белән муниципаль идарә итү системасын үстерү» ярдәмче программасы

«Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Мәдәният бүлеге» МКУ үзәкләштерелгән бухгалтериясе түбәндәге максатларны тормышка ашыру өчен оештырылган:

- бюджет чараларын тулаем һәм нәтиҗәле итеп куллануга ирешү;
- бухгалтер исәп-хисабының бердәм хокукый һәм методологик нигезләре буенча хисапны алып бару;
- хезмәт күрсәтелүче учреждениеләр эшчәнлеге турында тулы һәм дөреслеккә туры килә торган хисапны формалаштыру

Өлкә белән муниципаль идарә итү системасы үсешенә юнәлдерелгән чаралар

| № т/б | Программа чараларының исеме | Финансла у чыганак лары | Финансла у күләме, мең сум | Фаразланган финанслау күләме, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022ел | 2023ел | 2024ел |
| 1 | Өлкә белән муниципаль идарә итү системасын үстерү | Җирле бюджет | 5230.1 | 1537.4 | 1843.5 | 1849.20 |

## Мәдәният учреждениеләренең матди-техник базаларын ныгыту

Район мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту буенча килеп туган хәлгә анализ:

- 13 % мәдәният учреждениесенә капиталь төзекләндерү таләп итеlә;
- мәдәният учреждениеләренең биналарына ремонт таләп итеlә;
- мәдәният учреждениеләренең кирәкле дәрәҗәдә музыка җиһазлары белән җиһазландырылмавы.

Мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту өлкәсендә Программаның төп бурычлары булып тора:

- авыл мәдәният йортларының эчке биналары ремонты, клуб биналарының түбәләре ремонты авыл җирлекләре белән килештерү буенча;
- мәдәният учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;
- техник җиһазларны модернизацияләү, яктылык һәм тавыш - техника җиһазлары, музыка кораллары, китапханә һәм музей җиһазлары, компьютер техникасы, программа тәэмин итүен сатып алу.